Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18.05.2022 ел № 98

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2014 елның 17 ноябрендә кабул ителгән 252 номерлы «Кама Тамагы муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Кама Тамагы муниципаль районында муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, Кама Тамагы муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кама Тамагы муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2014 елның 17 декабрендәге 252 номерлы карарына, шулай ук Кама Тамагы муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктта “в” пунктчасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш

буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр килешү суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемннән артып китсә, һәм алыш-биреш кылуга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов